Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Миңлебай авыл Советы

КАРАРЫ

03 март 2020 ел №72

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл Советының 2006 елның 26 апрелендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл Советы депутаты статусы турында нигезләмә хакында»гы 15 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 40 статьясына үзгәрешләр кертү хакында” 2019 елның 26 июлендәге 228-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 13.1 статьясы нигезендә,

Миңлебай авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл Советының 2006 елның 26 апрелендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл Советы депутаты статусы турында нигезләмә хакында»гы 15 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 17 статьяның 3 пунктында:

а) 2 нче пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;»;

б) түбәндәге эчтәлекле 2.1. пунктчасын өстәргә:

«2.1) түбәндәге очраклардан тыш, коммерция яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга:

а) сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашу;

б) Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президентына (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) алдан хәбәр итеп, коммерциягә карамаган оешма идарәсендә (сәяси партия идарәсендә, һөнәри берлек органында, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешманың сайланулы органы, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтенең съездда (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашу;

в) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында җирлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тапшыру;

г) муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә куючы (катнашучы) булган оешманың идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә җирлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күрсәтү, оешманы гамәлгә куючы исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен, яки муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар»;

в) 3нче пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) укытучы, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта укытучылар, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән генә финанслана алмый, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса;»

г) 6 пунктта «җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты» сүзләреннән соң «яисә күрсәтелгән затларга карата җаваплылыкның башка чараларын» сүзләрен өстәргә;

д) түбәндәге эчтәлектәге 6.1., 6.2 пунктларын өстәргә:

«6.1. Үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында төгәл булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган депутатка, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, әгәр бу белешмәләрне бозуны җитди булмаса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) җирлек Советында депутат вазыйфасыннан азат ителү, аның вәкаләтләре чоры туктатылганчыга кадәр аны җирлек Советында биләү хокукыннан мәхрүм итү;

3) даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан аның вәкаләтләре чоры туктатылганчы, даими нигездә вәкаләтләр башкару хокукыннан мәхрүм итеп азат итү;

4) җирлек советында аның вәкаләтләре чоры туктатылганчы вазыйфа биләүне тыю;

5) вәкаләтләре чоры туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләр башкаруны тыю.»;

6.2. Депутатка әлеге статьяның 6.1 өлешендә күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы законы нигезендә муниципаль хокукый акт белән билгеләнә.».

е) 10 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Депутат «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәргә тиеш. «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән каралаган чикләүләр, тыюлар үтәлмәгән очракта, әгәр Федераль закон белән башкасы каралмаган булса, депутатның вәкаләтләре алда туктатыла»;

3. Әлеге карарны Миңлебай авылы, Ш.Бикчурин урамы, 50 нче йорт; Миңлебай станциясе, Шоссе урамы,20а йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүматлар порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Миңлебай авыл
җирлеге башлыгы И.М.Рәхимов